| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО<br>ЗЕМЕЛЬНЫХ И<br>ИМУЩЕСТВЕННЫХ<br>ОТНОШЕНИЙ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ<br>ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ<br>МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ<br>МИНИСТРЛЫГЫ |

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

27.06.2025 Казан ш. 2198-р

Газ бүлү челтәре объектларының саклык зонасын үзгәртү һәм Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасының Әлмәт, Лаеш, Питрәч муниципаль районнары, «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге территорияләрендә газ бүлү челтәрләре объектларының саклык зоналарын урнаштыру турында” 15.12.2021 № 3841-р боерыгына үзгәреш кертү турында

Россия Федерациясе Җир Кодексының 56, 106 статьяларына, «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы № 69-ФЗ Федераль законга, “Күчемсез милекнең дәүләт теркәве турында” 2015 елның 13 июлендәге № 218-ФЗ Федераль законның 32 статьясына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләренә туры китереп, «Газпром трансгаз Казань» ҖЧҖ мөрәҗәгате нигезендә һәм «Основание» кадастр үзәге» ҖЧҖ документациясенә туры китереп, «Татарстан Республикасы пространство мәгълүматы фонды» ДБУ хатын истә тотып (11.06.2025 № 01А-04/1069), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәсенә таянып:

1. Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасының Әлмәт, Лаеш, Питрәч муниципаль районнары, «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге территорияләрендә газ бүлү челтәрләре объектларының саклык зоналарын урнаштыру турында” 15.12.2021 № 3841-р боерыгының (алга таба - № 3841-р Боерык) 5 пункты белән урнаштырылган, «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә «Газпром трансгаз Казань» милке булган газ бүлү челтәре объектларының саклык зонасын («Бүлгеч газүткәргечләрнең саклык зонасы (16:00:000000:907, 16:50:000000:18497, 16:50:000000:19662, 16:50:000000:19738, 16:50:000000:19141, 16:50:000000:19833, 16:00:000000:681, 16:50:000000:19270, 16:50:000000:18984,16:50:000000:19121)»), 16:50:210202:588, 16:50:200301:1, 16:50:210202:584 кадастр номерлы җир кишәрлекләрендәге урта басымлы газүткәргечне демонтажлау сәбәпле, территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текстлы һәм график тасвирламасындагы мәгълүмат, җир өсте һәм җир асты объектларының характерлы нокталарының координаталары исемлегенә туры китереп үзгәртергә.

Газ бүлү челтәренең саклык зонасы гомуми мәйданы (36742 +/- 67) кв.м.лы территория рәвешендә 1190 м. озынлыкны тәшкил итә.

2. Газ бүлү челтәрен («Бүлгеч газүткәргечләрнең саклык зонасы (16:00:000000:907, 16:50:000000:18497, 16:50:000000:19662, 16:50:000000:19738, 16:50:000000:19141, 16:50:000000:19833, 16:00:000000:681, 16:50:000000:19270, 16:50:000000:18984,16:50:000000:19121)») эксплуатацияләү срогына газ бүлү челтәрләренең саклау зоналары чикләренә тулысынча яки өлешчә туры килгән җир кишәрлекләренә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган газ бүлү челтәрен саклау кагыйдәләрендә каралган чикләүләр (йөкләүләр) кертергә.

3. Территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текстлы һәм график тасвирламасындагы мәгълүмат, җир өсте һәм җир асты объектларының характерлы нокталарының координаталары исемлеге нигезендә, 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, № 3841-р Боерыгына үзгәреш кертергә:

«5. Татарстан Республикасының «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә («Бүлгеч газүткәргечләрнең саклык зонасы (16:00:000000:907, 16:50:000000:18497, 16:50:000000:19662, 16:50:000000:19738, 16:50:000000:19141, 16:50:000000:19833, 16:00:000000:681, 16:50:000000:19270,

16:50:000000:18984,16:50:000000:19121)») урнашкан газ бүлгеч объектларының саклык зонасын (36742 +/- 67) кв.м гомуми мәйданлы 1190 м. озынлыктагы саклык зонасын территорияне файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре урнашкан урынның текстлы һәм график тасвирламасындагы мәгълүмат, җир өсте һәм җир асты объектларының характерлы нокталарының координаталары исемлегенә туры китереп урнаштырырга.».

**Министр**
**А.Р.Кадыйров**